| Каралган | Килешенгән | Раслыйм |
|---|---|---|
| МБ житәкчесе | «Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ нең УТЭБДУ | «Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ |
| _____ /Калинина М.Б./ | _____ /Сәгъдиева Г.Ф./ | директоры |
| Беркетмә № 1 | «25»август 2014 ел. | _____ / Әхмәтшина О.М./ |
| «25»август 2014 ел. | | Приказ № 94 |
| | | «27»август 2014 ел. |

Уку фәненнән

# ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы

“Яңа Мәлкән УГБМ” ГБМУ

Исрафилова Рәзилә Минегали кызы, I квалификацион категорияле укытучы

татар теле, 4 нче сыйныф

Педагогик совет
утырышында каралган
беркетмә № ___
« 25 » август 2014 ел.

2014 – 2015 нче уку елы

## Аңлатма язуы

**Татар теленнән эш программасы ФДБС таләпләренә** туры килә.**Эш программасы** “Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә ана теле укыту: гомуми программа”(1 – 4 нче сыйныфлар.Т ө з ү ч е - а в т о р л а р ы : Ч. М. Харисова, И. Х. Мияссарова, Ф. Ш. Гарифуллина; Казан 2011) га һәм Татарстан Республикасы Минзәлә районы” Яңа Мәлкән төп гомуми белем бирү мәктәбе”нең укыту планына нигезләнеп төзелде.
Программаны үзләштерүгә бирелгән сәгатьләр саны: 105. Атнага 3 сәгать.
**УМК “Перспективалы башлангыч мәктәбе”**
***Эш программасы структурасы***. Татар теленнән эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.
***Эш программасының эчтәлеге.*** Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, **«укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш”**. Бу – яңа стандартта **эшлекле белем** дип атала**. Эшлекле белем** – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата.
**<u>Татар теленә өйрәтүнең бурычлары түбәндәгеләр:</u>**

1. Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш уяту, үз милләтеңә һәм аның теленә мәхәббәт тәрбияләү.
2. Балаларда татар теленең барлык бүлекләре буенча мәгълүматлылыкны (компетенцияне) булдыру.
3. Укучыларда коммуникатив компетенция булдыру. Аралашканда тел чараларыннан урынлы файдаланырга өйрәтү.
4. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру.
5. Укучыларда татар мәдәниятенә караган мәгълүматлылыкны үстерү.

**<u>Татар теле укытуның максатлары:</u>**

- укучыларда уңышлы аралашу сәләте булдыру- әйтмә һәм язма сөйләмне үстерү, кара-каршы сөйләшү осталыгы, монолог төзү һәм шулай ук гомуми культура күрсәткече булган грамоталы язу күнекмәләре булдыру, укучыларны тел фәнең төп тәгълиматлары белән таныштыру һәм шулар нигезендә аларның тамга-символик һәм логик фикерләвен үстерү
- укучыларның фикерләү сәләтен үстерү, тел чараларын аралашуның эчтәлегеннән чыгып билгели белү, балаларның ана телендә аралашу күнекмәләрен камилләштерү;
- телнең фонетика, лексика, грамматикасы буенча башлангыч белем алу, өйрәнелә торган тел берәмлекләрен тикшерә белү күнекмәләрен булдыру,
- дөрес уку һәм дөрес язу күнекмәләрен булдыру, диалогик сөйләмдә катнашу, гадирәк итеп төзелгән монологик сөйләм оештыру;
- укучыларда ана теленә хөрмәт һәм ярату тәрбияләү, телнең чисталыгын, дөреслеген саклау, тел өйрәнүгә кызыксыну өйрәтү.

**Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы.**

**Тыңлап аңлау.** Сөйләмдәге сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне аңлау, аларны бер-берсеннән аеру. әйтелгән фикердәге мөһимрәк булган вакыйгаларың эзлеклелегенә төшенү.Тыңлый белүне уңышлы аралашуның шарты, кара-каршы сөйләшүнең нигезе икәнен үзләштерү.
**Сөйләү.** Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен гамәли үзләштерү. Укуга һәм конкрет тормышка кагылышлы темалар буенча әңгәмә кору.Укылган текстка сорау кую, аның эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга җавап бирү, планын төзү. Укучыларга якынрак булган темалар буенча сөйләшү. Гадирәк җөмләләрдән төзелгән төрле темаларга кагылышлы монологик сөйләм оештыра белү, интонация үзенчәлекләрен үзләштерү. Сөйләм этикеты үрнәкләреннән дөрес файдалану.
**Уку.** Әкиятләрне, кечкенә хикәяләрне, дәреслектәге текстларны аңлап, дөрес, йөгерек итеп укый белү. Текстның төп фикерен аңлап, темасын билгели алу, кирәкле урыннарын сайлап уку. Гади план төзеп, текстның эчтәлеген сөйләү һәм укучының текстка мөнәсәбәтен белдерү.Укыганның эчтәлегенә, тел үзенчәлекләренә, төзелешенә бәя бирү. Информацияне аңлата һәм гомумиләштерә алу.
**Язу.** Язма сөйләм белән телдән сөйләмнең аермасы. Җөмләне тексттан аера белү. Хат һәм төрле котлау текстлары язу. Өйрәнелгән кагыйдәләргә нигезләнеп текстларны күчереп, ишетеп язу.Үзлегеннән зур булмаган текстлар иҗат итү.

**<u>Татар теле предметының укыту планындагы урыны</u>**

Программа гамәлдәге базис план һәм ТР Минзәлә муниципаль районы МБОУ “Яңа Мәлкән төп мәктәбе” нең 2014-2015 нче уку елына уку – укыту планы нигезендә атнага 3 сәгать исәбеннән 35 атнага төзелә, база дәрәҗәсендә. Барлык сәгать саны -105 сәг, база дәрәҗәсендә.

## Укыту курсы темалары эчтәлеге:

1—3 **нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау**

(8 сәгать)

4 нче сыйныфта татар теле дәресләре 1—3 нче сыйныфларда алынган белемнәрне искә төшерүдән башлана.

1—3 нче сыйныфларда укучылар тел фәненең төп бүлекләре — татар теленең фонетикасы, морфологиясе һәм синтаксисы буенча иң беренче мәгълүматларны алалар.

Фонетикадан, мәсәлән, аваз һәм хәреф, алар арасындагы аерма, тартык һәм сузык авазлар, аерым авазларның дөрес әйтелеше, дөрес язылышы өйрәнелә, сингармонизм законы турында беренче күзаллау тудырыла. Морфология буенча башлап сүз төзелеше (тамыр һәм кушымча, кушымчаларның төрләре) һәм аерым сүз төркемнәре (исем, сыйфат, алмашлык, фигыль, кисәкчә, бәйлек) өйрәнелә. Синтаксистан исә җөмлә һәм аның төрләре (хикәя җөмлә, сорау җөмлә, өндәү (боеру) җөмлә, тойгылы җөмлә); җөмлә кисәкләре, җыйнак һәм җәенке җөмләләр, сүзтезмә турында башлангыч мәгълүматлар бирелә.

4 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау өлешендә фонетика, морфология һәм синтаксистан үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү күздә тотыла. Программада моңа барысы 8 сәгать бирелгән. Кабатлау дәреслектәге 1—22 нче, эш дәфтәрендәге 1—12 нче күнегүләр өстендә алып барыла.

**Сүз. Телнең сүзлек байлыгы. Сүзнең лексик мәгънәсе**

(8 сәгать)

Дәреслектәге «Сүз. Телнең сүзлек байлыгы. Сүзнең лексик мәгънәсе» темасын кабатлау өчен бирелгән күнегүләрдә (дәреслектәге 23—52 нче, эш дәфтәрендәге 13—23 нче күнегүләр) сүзнең лексик мәгънәсе, алынма сүзләр, бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр, тотрыклы сүзтезмәләр, омоним, синоним, антонимнарны искә төшерү бурычы куела. Татарча-русча яки русча-татарча сүзлек, орфографик сүзлек, аңлатмалы сүзлек, фразеологик әйтелмәләр сүзлеге белән эшләү күнекмәләре ныгытыла.

Сүз төзелеше

(11 сәгать)

4 нче сыйныфта кабатлау дәресләренең төп максаты — укучыларның 1—3 нче сыйныфларда алган белемнәрен искә төшерү.

«Сүз төзелеше» темасын кабатлау һәм тирәнәйтү өчен бирелгән күнегүләрдә дә (дәреслектәге — 53—80 нче, эш дәфтәрендәге 24—40 нчы күнегүләр) тамыр һәм кушымчаларны аера белү, кушымчаларның ясагыч һәм төрләндергечләргә бүленүен, сүзләрнең ясалыш буенча төрләрен (кушма, парлы сүзләр) искә төшерү бурычы куела.

4 нче сыйныфта «сүз төзелеше» темасы тагын да тирәнәйтелә: ясалма, кушма, парлы, тезмә сүзләрнең ясалышы һәм язылы-шы; рус теленнән татар теленә кергән алынма кушма сүзләрнең үзенчәлекләре; сүз төзелешенә анализ ясау h.б. яңа темалар белән баетыла. Дәреслектәге кайбер күнегүләрдә өстәмә биремнәр рәвешендә кушымчаларның төрле вариантларын (калын һәм нечкә кушымчалар, яңгырау, саңгырау һәм борын авазларына башланган кушымчалар), сингармонизм законына буйсынмаган сүзләргә сүз ясагыч кушымчаларның ялгану тәртибен, кайбер кушма сүзләрдә ь һәм **ъ** хәрефләренең язылыш кагыйдәләрен аңлату һәм ныгыту да күздә тотыла.

**Сүз төркемнәре**

**Исем (8 сәгать)**

Мәгънәсе, сораулары, формалары, ясалышы, җөмләдәге урыны турында кабатлау. Исемнәрнең хәбәр булып килүләрен.» күзәтүләр. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Берлек һәм күплек сандагы исемнәр. Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше. Калын һәм нечкә төрләнеш. Сингармонизм законына буйсынмаган сүзләргә кушымча ялгау. Килеш кушымчаларының, дөрес язылышы.

Баш килеш. Бу формада исемнәрнең җөмләдә ия, хәбәр, ияр чен кисәк була алулары. Төшем килешенең мәгънәсе, җөмләдәге функциясе.

«Исем» темасын кабатлау, ныгыту, тирәнәйтү дәреслектән — 81—111 нче, эш дәфтәреннән 41—52 нче күнегүләр өстендә башкарыла.

Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше. Тартым кушымчаларының исемнәргә нинди мәгънә өстәгәнлекләрен аңлату өчен дәреслектән, 98 нче күнегү тәкъдим ителә. Күнегүдә тартымлы исемнәр калын хәрефләр белән бирелгән. Шул сүзләрне укытучы тамыр һәм кушымчаларга аерырга куша: *бит-лә-рем, авыз-ым, колачым, күз-ләр-ем, теш-ләр-ем, кул-лар-ым.*

— Бу сүзләрдәге -ым/-ем кушымчалары исемнәргә нинди мәгънә өсти?

— Предметның ничәнче затка караганлыгын белдерә.

— *Битең, авызың; бите, авызы; битебез, авызыбыз; битегез, авызыгыз; битләре, авызлары* сүзләрендә -ың/-ең; -ы/-е; -ыбыз/-ебез; -ыгыз/-егез; -лары/-ләре кушымчалары предметның ничәнче затка караганлыгын белдерә? кебек сораулар бирелә. Укучыларның җаваплары тыңлангач, билгеләмә укытыла.

Тартым предметның затка караганлыгын белдергәнгә күрә, аның III заты һәм берлек, күплек формалары була. Шунлыктан булса кирәк, укучылар еш кына исемнең тартым белән төрләнүен зат белән төрләнү дип әйтергә гадәтләнәләр. Бу ялгышны вакытында кисәтергә кирәк. Сыйныф бүлмәсенә «Исемнәрнең тартым белән төрләнеше» дигән таблица эленә. Укучылар, шул кушымчаларның һәр төре ялганырлык исемнәр уйлап, дәфтәрләренә исемнәрне тартым белән төрләндереп язалар һәм үзләре «Сузыкка беткән исемнәргә тартым кушымчаларының тартыктан башланганнары, ә тартыкка һәм [у], [ү] авазларына беткән исемнәргә сузыктан башланган кушымчалар ялгана», дигән нәтиҗә чыгаралар.

*Әти, әни* кебек сүзләрнең бу кагыйдәләрдән чыгарма булуын искәрмә рәвешендә әйтеп китәргә кирәк: «Сузыкка бетсәләр дә аларга I һәм II зат тартым кушымчаларының сузыкка башланганы ялгана *(әнием, әни-ем* h.б.)».

**Фигыль**

**(13 сәгать)**

Фигыль — катлаулы сүз төркеме.

Н и ш л и ? н и ш л ә д е ? сорауларына җавап булып килгән һәм предметның эшен, хәрәкәтен белдергән сүзләр 1 нче сыйныфта ук өйрәнелә. 2 нче сыйныф дәреслегендә эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр турында махсус бүлек кертелә һәм сораулар өстәлә: н и ш л и ? н и ш л ә д е ? н и ш л ә г ә н ? н и ш л ә р ? н и ш л и л ә р ? н и ш л ә д е л ә р ? н и ш л ә г ә н н ә р ? н и ш л ә р л ә р ?

3 нче сыйныфта фигыльнең барлыкта һәм юклыкта килүе; хикәя фигыльнең үткән, хәзерге һәм киләчәк заманнары;
фигыльләрнең күп мәгънәлелеге буенча шактый тулы мәгълүмат бирелә.

4 нче сыйныфта 1—3 нче сыйныфта үткән материал искә төшерелә һәм хикәя фигыльнең билгеле үткән заман, нәтиҗәле үткән заман формалары; киләчәк заман формалары: билгесез киләчәк заман, билгеле киләчәк заман турында яңа мәгълүмат өстәлә.

Фигыль төркемчәләреннән боерык фигыль дә 4 нче сыйныфта өйрәнелә башлый. Аңа бирелгән өч сәгатьне түбәндәгечә бүләргә мөмкин: беренче сәгатьтә боерык фигыльнең мәгънәсен һәм зат-сан белән төрләнешен өйрәнеп, ике сәгатьне боерык фигыльне куллану һәм дөрес язуга бирергә була. Боерык фигыльләрнең язылышында I затның берлеге һәм күплеге кыенлык тудыра. Программада боерык фигыльләрнең II, III затта берлек һәм күплек формалары турында гына мәгълүмат бирү каралса да, укытучылар игътибарына боерык фигыльнең I зат берлеге һәм күплеге язылышына караган кагыйдәләрне тәкъдим итәбез:

1) Сузык авазга тәмамланган фигыльгә **-ыйм/-им, -ыйк/-ик**
кушымчалары ялганганда, нигезнең соңгы сузыгы төшеп кала:
кара ---------*карыйм; телә*-------------- *телим; төя — (төйә) — төй \ им;*
*укы* -------- *ук-ыйм; төзе*-------------*төзим* һ. б. Ләкин *бие — (бийе) бий-*
*им* түгел; бу очракта **й** язылмый һәм бу фигыльнең I заты *укы-, төзе-* фигыльләреннән ясалган кебек үк ясала: *биим, (төзим, ук-ыйм кебек).*

2) Нигезләре **[й]** һәм [у] авазларына тәмамланган фигыльләргә **-ыйм/-им, -ыйк/-ик** кушымчалары, тартыкка беткән фигыльләргә кушылгандагы кебек, бернинди үзгәрешсез ялгана: *куыйм, шуыйм, җәйим, төй-им.*

3) Фигыльнең нигезе дифтонгка тәмамланганда, и к е с у зык арасына туры килгән у урынына **в** языла: *сау* *савыйм,*
*савыйк, савыгыз.*

Дәреслектә фигыльнең җөмләдә хәбәр булып килүе, антоним һәм синоним фигыльләр турында да мәгълүмат бирелә.

Бу темага дәреслектән — 112—153 нче, эш дәфтәреннән 53— 71 нче күнегүләр тәкъдим ителгән.

## Сыйфат
## (7 сәгать)

**Сыйфат** — предметның билгесен белдерә торган сүз төркеме. У л , нигездә, төрләнми. Тик кайбер сыйфатларны гына дәрәҗәгә куеп була.

Җөмләдә сыйфат исемне ачыклап килә һәм күбесенчә аергыч була.

Укучыларга сыйфат турында төшенчә 1—3 нче сыйныфларда ук бирелә. 1 нче сыйныфта, мәсәлән, укучылар н и н д и ? к а й с ы ? соравына җавап булып килгән сүзләрнең предметның билгесен белдерүе белән танышалар.

2 нче сыйныфта сыйфат сүз төркеме турында укучыларның белемнәре шактый тирәнәйтелә. Алар сыйфатларның төрле билге (төс, тәм, форма, характер һ. б.) белдерүләре белән танышалар, синоним һәм антоним сыйфатлар турында да мәгълүмат алалар.

3 нче сыйныфта укучылар сыйфатның җөмләдәге функцияләре, ягъни аергыч һәм хәбәр булып килүе белән дә танышалар. Сыйфат дәрәҗәләре турында да шактый мәгълүмат бирелә.

4 нче сыйныфта да, үтелә торган материалга бәйләп, сыйфат дәрәҗәләре, сыйфатның җөмләдәге функциясе (аергыч, хәбәр), синоним һәм антоним сыйфатларны кабатлап баруны күз алдында тотарга кирәк.

Дәреслектәге — 1—1 9 нчы һәм эш дәфтәрендәге 7 2 —83 нче күнегүләр нигезендә укучыларның сыйфат турындагы белемнәрен тирәнәйтү, кайбер яңа мәгълүматлар бирү, бу сүз төркеме буенча ныклы күнекмәләр булдыру күздә тотыла.

## Алмашлык
## (6 сәгать)

**Алмашлык** — мөстәкыйль сүз төркеме. Ул сөйләмдә башка сүз төркемнәрен (исем, сыйфат, сан һәм рәвешне) алыштырып килә.

Алмашлык предметны яки билгене белдерми, ул бары тик үзе алыштырып килә торган сүз төркеменең грамматик билгеләренә ия була.

Укучылар алмашлыкларны, сүз төркеме буларак, 3 нче сыйныфта өйрәнә башлыйлар. Аларга бу сыйныфта нигездә зат алмашлыклары турында мәгълүмат бирелә. Зат алмашлыкларына **мин** — без, **син** — сез, **ул — алар** сүзләре керү, аларның җөмләдә исемне алыштырып килүләре, килеш белән төрләнүләре турында укучылар шактый тирән белем алалар, 4 нче сыйныфта зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше, дөрес язылышы кабатлана һәм сорау алмашлыклары турында яңа мәгълүмат бирелә.

Сорау алмашлыклары темасына кереп китү өчен, укучылардан килешләрне барлык сораулары белән әйттереп чыгарга кирәк.

Б. к. к е м ? н ә р с ә ?
И. к. к е м н е ң ? н ә р с ә н е ң ?
Ю. к. к е м г ә ? н ә р с ә г ә ? к а я ?
Т. к. к е м н е ? н ә р с ә н е ?
Ч. к. к е м н ә н ? н ә р с ә д ә н ? к а й д а н ?

Ур.-в. к. к е м д ә ? н ә р с ә д ә ? к а й д а ? к а й ч а н ?

Димәк, килеш сораулары сорау алмашлыкларына керәләр. Сорау алмашлыкларына тагын нинди, кайсы, ничек, ник, нигә, ничәнче кебек сүзләр керә.

Дәреслектә бирелгән 20—3 5 нче һәм эш дәфтәрендәге 84— 88 нче күнегүләр бу теманы тулырак аңларга ярдәм итәр.

**Сан**
**(6 сәгать)**

Сан предметның исәбен, микъдарын белдерә торган сүз төркеме. Сан исем белән кулланылганда төрләнми. Җөмләдә ул аергыч, хәбәр һәм исемнән башка кулланылганда, җөмләнең бүтән кисәкләре дә була ала. Мәсәлән: *Бүген кызларның* *<u>икесе</u>* *дә авырып китте. Дәрестә биш укучы шигырь сөйләде. Биш бишең —* *<u>егерме биш</u>*.

Фигыльне ачыклап килгәндә, сан хәл дә була. *Бер сорады, ике сорады — Азат чанасын бирмәде.*

Кайбер очракларда сан, саналмышы белән, бер җөмлә кисәге тәшкил итә: *Су коенырга* ***икешәр мәртәбә*** *барабыз. Мин* ***дүртенче сыйныфта*** *укыйм.*

Сүз төркеме буларак, сан 4 нче сыйныфта өйрәнелә башлый. Укучылар санның билгеләмәсе (мәгънәсе, сораулары) белән танышалар. Санның исемне ачыклап килүе, сан белән ачыкланып килгән исемнең саналмыш булуы, кайбер сан төркемчәләре (микъдар саннары, тәртип саннары) турында беренче мәгълүмат алалар.

Дәреслектәге — 36—6 1 нче, эш дәфтәрендәге 89—97 нче күнегүләр укучыларның сан төркемчәләре турында белемнәрен ныгыту өчен тәкъдим ителә.

**Рәвеш**
**(5 сәгать)**

Рәвеш — мөстәкыйль сүз төркеме, лексик-грамматик яктан эш-хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә.

Морфологик яктан — төрләнми. Тик кайбер рәвешләр генә чагыштыру яки артыклык дәрәҗәсендә килә алалар: ***Иң элек*** *бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән... (Г. Тукай). Мин быел чаңгыда* ***шәбрәк*** *йөрим.*

Синтаксик яктан — җөмләдә фигыльне, сыйфатны һәм рәвешне дә ачыклап килә.Төп синтаксик функциясе — хәл.

Укучыларга рәвеш турында башлангыч мәгълүмат 4 нче сыйныфта бирелә. Аның н и ч е к ? к а й ч а н ? к а я ? к а й д а ? н и к а д ә р ? к ү п м е ? кебек сорауларга җавап булып килүе, эш яки хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә торган сүз төркеме булуы аңлатыла.

Рәвеш сүз төркемен өйрәнгәндә, фигыльне кабатлауга зур мөмкинлекләр бар, чөнки рәвеш күбрәк фигыльне ачыклап килә. Мондый мөмкинлектән файдаланырга тырышу бик урынлы. Дәреслектәге — 51—61 нче, эш дәфтәрендәге 94—99 нчы күнегүләр укучыларның рәвеш сүз төркеме турында белемнәрен ныгыту өчен тәкъдим ителә.

**Кисәкчәләр**
**(2 сәгать)**

Кисәкчәләр турында беренче мәгълүмат 3 нче сыйныфта бирелә.

4 нче сыйныфта кисәкчәләрнең сүз яки җөмләгә төрле төсмер өстәү өчен кулланылуы ачыклана. Димәк, кисәкчәләр, аерым торганда, мәгънә белдерми, бәлки контекст эчендә генә ал арның мәгънәләре конкретлаша икән. Бик күп кисәкчә күп мәгънәле була, һәм аларның мәгънә төсмерләре нинди сүзгә иярүләренә, кайсы урында килүләренә, җөмлә төзелешенә, аның интонациясенә карап үзгәрә.

Дәреслектәге — 6 2 —68 нче, эш дәфтәрендәге 100—101 нче күнегүләр укучыларның кисәкчәләр турында белемнәрен тирәнәйтү өчен тәкъдим ителә.

**Бәйлекләр**
**(2 сәгать)**

**Бәйлекнең** ярдәмлек сүз төркеме булуы турындагы башлангыч төшенчә 1 нче сыйныфта бирелә, 2—3 нче сыйныфларда ныгытыла, тирәнәйтелә.

Ярдәмлек сүз булганга, төшенчәдә төп урынны бәйлекнең функциясе, үтәгән хезмәте алып тора: бәйлекләр сүзләрне бәйлиләр икән. Бәйлекләр, сүзләрне бәйләгәндә, килешкә якын мәгънә белдерәләр.

Бәйлекләр үзләреннән алда килгән сүзнең билгеле килештә торуын сорыйлар. **Бу** килешләр өчәү: *баш, юнәлеш* һәм *чыгыш килеше.* Шуңа карап, бәйлекләр дә өч төркемчәгә аерыла.

4 нче сыйныфта төрле килешләрдә исемнәрнең һәм зат ал-машлыкларының бәйлекләр белән килүенә йомгак ясала, си-стемалаштырыла, бәйлек төшенчәсе грамматик категория итеп аңлатыла.

Бу темага дәреслектә 6 күнегү (69—74 нче), эш дәфтәрендә 3 күнегү (102—104 нче) бирелгән.

**Җөмлә. Сүзтезмә**
**(2 сәгать)**

**Сүзтезмә** турында башлангыч аңлатма 3 нче сыйныфта бирелә.

4 нче сыйныфта сүзтезмәләргә шактый эзлекле мәгълүмат бирү күздә тотыла: сүзтезмә һәм тезмә сүзләр арасындагы аерманы аңлату, сүзтезмәләрнең барлыкка килү юлларын ныгыту, сүзтезмәдәге иярүче һәм ияртүче сүз турында белемнәрне тирәнәйтү һ. б.

Дәреслектәге 7 5 —81 нче күнегүләр бу теманы ныгыту һәм тирәнәйтү өчен тәкъдим ителә.

**Җөмләнең баш кисәкләре**
**Ия һәм хәбәр**
**(2 сәгать)**

Бу тема 2—3 нче сыйныфта өйрәнгәннәрне кабатлау төсендә бара. Ия белән хәбәрнең билгеләмәсе әйттерелә, хәбәрнең сораулары мисаллар белән ныгытыла.

Җөмләдә бер мөстәкыйль исем яки зат алмашлыгы белән белдерелгән ияне табу кыенлык тудырмый. Исем мәгънәсендә килгән сүз яки сүзләр белән белдерелгән ияне табу да читен түгел. Шик туган очракта, аның я нинди исем урынында (мәгънәсендә) килүен ачыкларга, я җөмләнең хәбәре аша **тик**шереп карарга кирәк.

Гади хәбәр я бер мөстәкыйль сүз, яки бер тезмә сүз, яисә хәбәрлек сүз белән белдерелгәнгә, аны мөстәкыйль рәвештә танып белү кыенлык тудырмый.

Теманы ныгыту өчен дәреслектән — 82—87 нче, эш дәфтәреннән 107—108 нче күнегүләр эшләнә.

**Җыйнак һәм җәенке җөмләләр**
**(1 сәгать)**

**Җыйнак һәм җәенке** җөмләләр турында 3 нче сыйныфта беренче мәгълүмат бирелде.

4 нче сыйныфта җыйнак җөмләне, тиешле сүзләр өстәп, җәенкеләндерә белү, җәенке җөмлә эченнән баш кисәкләрне генә аерып чыгару кебек күнегүләр эшләнә. Моның өчен дәреслектән 88— 90 нчы, эш дәфтәреннән 109 нчы күнегү тәкъдим ителә.

**Җөмләнең иярчен кисәкләре**
**Аергыч**
**(1 сәгать)**

Бу материалны укучылар мөстәкыйль рәвештә дә үзләштерә ала. Әгәр дә алар, аергыч турында 2—3 нче сыйныфларда үткәннәрне исләрендә тотсалар, аергычка билгеләмәне һәм аның белдерелүен әйтеп бирә алалар.

4 нче сыйныфта аергычның сыйфат белән белдерелүе дәреслектәге — 91—94 нче, эш дәфтәрендәге 1 1 0 нчы күнегүләр өстендә ныгытыла.

**Җөмләнең тиңдәш кисәкләре**
**(1 сәгать)**

Җөмләнең **тиңдәш** кисәкләрен һәм тиңдәш кисәкләрнең үзара санау интонациясен, теркәгечләр ярдәмендә бәйләнешен төшендерү; тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләренең куелышын аңлату. Тиңдәш ияле һәм тиңдәш хәбәрле җөмләләр. Тиңдәш кисәкләр арасында **һәм,** я , **да/дә, та/тә, ә, ләкин** теркәгечләре, тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре.

Дәреслектәге — 95—99 нчы һәм эш дәфтәрендәге 1 1 1 нче күнегүләр нигезендә укучыларның тиңдәш кисәкләр турындагы белемнәре ныгытыла.

**Эндәш сүзләр (1 сәгать)**

Укучыларга **эндәш** сүзләр турында төшенчә бирү. Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләрен куярга өйрәтү.

Дәреслектәге — 100 —103 нче һәм эш дәфтәрендәге 1 1 2 нче күнегүләр нигезендә укучыларның эндәш сүзләр турындагы белемнәре ныгытыла.

**Гади һәм кушма җөмлә**
**(2 сәгать)**

Гади һәм кушма җөмләләр турьҗда төшенчә бирү. Составында 2—3 гади җөмлә булган кушма җөмләләр. Андый җөмләләрне тиңдәш кисәкле җөмләләрдән аера һәм ал арны тикшерә белү. Тезмә кушма җөмләләрдә **һәм, ә, ләкин, әмма** теркәгечләре, алар янында тыныш билгеләре.

Дәреслектәге — 104—108 нче, эш дәфтәрендәге 113—114 нче күнегүләр укучыларның гади һәм кушма җөмлә турында белемнәрен ныгыту өчен тәкъдим ителә.

4 **нче сыйныф** укучыларының **белем** дәрәҗәләрендә булачак нәтиҗәләр

— сүзләрдәге орфограммаларны танып, ал арның язылышын кагыйдәләргә нигезләнеп аңлату;
— үтелгән орфограммалар кергән 7 5 —80 сүзле текстны хатасыз, каллиграфик күчереп һәм ишетеп, тиңдәш кисәкләр янында тиешле тыныш билгеләрен дөрес куеп язу;
— *дөнья, болыт* тибындагы сүзләргә аваз-хәреф анализы ясау;
— сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерү: тамырын һәм кушымчасын табу, кушымчаларның төрен билгеләү, кушма һәм парлы сүзләрне аерып күрсәтү;
— сүзләрне сүз төркеме булу ягыннан тикшерү: исемнең сан, килеш формасын күрсәтү; сыйфатларның асыл, нисби төрен, чагыштыру дәрәҗәсен билгеләү; фигыльнең зат-сан, заманын аера белү; һәр сүз төркеменең җөмләдәге функциясен билгеләү;
— тиңдәш кисәкле гади җөмләгә, составында 2—3 гади җөмлә булган тезмә кушма җөмләгә анализ ясау;
— җөмләләрнең әйтелү максаты, интонациясе буенча төрен икеләнмәстән аеру;

— текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү, шулар нигезендә аңа килешле исем кую;
— хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү тибындагы текстларны сөйләмдә куллану;
— әдәпле мөгамәлә таләпләренә туры китереп аралаша белү;
— тасвирлау, фикер йөртү элементлары кергән 90—95 сүзле текстны изложение итеп язу;
— хикәяләү тибындагы сочинение язу;
— сүзләрнең әйтелешен, кулланылышын, язылышын истә калдыру: *авыру, аз-маз, ата-ана, ашханә, аңлый, әби-бабай, әверелә, әүвәл, балачак, бәла, бернichә, борынгы, вакыйга, ватык, гадәт, гомер, дәвам, җәяү, җәпшек, җиләк-җимеш, зинһар, иелә, ихтирам, йомры, кадәр, кием-салым, кульязма, көнбатыш, көнчыгыш, көрәшче, кыйммәтле, мал-туар, мәйдан, мәкалә, могҗиза, мөстәкыйль, нәкъ, охшаш, очсыз, өем, өчпочмак, пәрәвез, рәссам, савыт-саба, сәнгать, сөңге, сурәт, табиб, табигый, таләп, тәкъдим, тәмам, тирә-як, төер, туптуры, тынгылык, чүп-чар, шагыйрь, шәфәкъ, шыңшый, эшчән, юеш, юньле, юучы, ямьле, ямь-яшел, япъ-яшь.*

## Планлаштырылган универсаль уку гамәлләре

Программа белән эшләүнең төп максаты – 4 нче сыйныф ахырына планлаштырылган (яки көтелгән) нәтиҗәләргә ирешү. Алар түбәндәгеләр:

**Шәхси нәтиҗәләр**

1. **“**Гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, “башкаларга карата түземлелек” төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү;
2. Туган республикага, гаиләгә, туганнарга карата хөрмәт, әти-әнине ярату; үз милләтеңне ярату, татар булуың белән горурлану;
3. Укуга карата кызыксыну хисе булу, укучы ролен үзләштерү;
4. Әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләрен һәм геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

1. Уку хезмәтендә үзеңә максат куя белү, бурычларны билгели белү;
2. Эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;
3. Уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
4. Укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;
5. Укудагы уңышларга,уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;.
6. Дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли белү, алар белән дөрес эш итә белү;
7. Дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**

1. Уку максатын мөстәкыйль билгеләү;
2. Тиешле мәгълүматны табу, билгеләү;
3. Сөйләм берәмлекләрен логик тәртипкә салу;
4. Мәсьәләне чишү өчен уңайлы ысул сайлау;
5. Эш башкаруның ысулларына һәм шартларына анализ ясау;
6. Эшчәнлек процессында контроль һәм бәя бирү;
7. Аңлап уку, тиешле мәгълүматны сайлап алу, төп мәгълүматны аеру;
8. Иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
9. Төп һәм ярдәмчел билгеләрне аеру, анализлау;
10. Объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
11. Төшенчәгә якын килү өчен нәтиҗә ясау;
12. Фикерләрне логик чылбырга салу;
13. Иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы чишү ысулларын мөстәкыйль рәвештә булдыру

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

1. Әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аралашу күнекмәләрен формалаштыру;
2. Күмәк эшне планлаштыру;
3. Әңгәмәдәшнең фикерен тыңлый белү;

4. Әңгәмәдәш аралашу калыбын төзү;
5. Мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару;
6. Әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү;
7. Коммуникатив мәсьәләгә таянып фикерне төгәл итеп җиткерү.

**<u>Укучыларның белем һәм күнекмәләренә төп таләпләр</u>**

**Укучылар беләчәк:**

-сүзнең мәгънәле кисәкләре: тамыр һәм кушымча, ясагыч кушымча, төрләндергеч кушымча;
- сүз төркемнәре: исем, сыйфат, фигыль, кисәкчә, бәйлек.
- җөмләнең баш кисәкләре: ия һәм хәбәр.
- җөмләнең иярчен кисәкләре (төрләргә бүлмичә)

**Укучылар башкара алачак:**

-үтелгән орфограммалар (калын һәм нечкә сузыклар, яңгырау һәм саңгырау тартыклар, парсыз тартыклар, нечкәлек һәм аеру билгеләре, кушма һәм парлы сүзләр, тамырда авазлар чиратлашуы, кисәкчәләр) кергән 55 – 60 сүзле текстны, җөмлә ахырында тиешле тыныш билгеләрен куеп, диктант итеп язу.
-текстларны грамоталы һәм каллиграфик дөрес күчереп язу.
- сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерү(тамыр һәм кушымчаларны аеру, кушымчаларның төрен билгеләү, тамыр, ясалма, кушма һәм парлы сүзләрне аерып күрсәтү).
- сүз төркемнәрен һәм аларның грамматик билгеләрен тану, аеру (исемнең санын, килешен, фигыльнең затын, заманын);
- берлек сандагы исемнәрне килеш белән төрләндерү
- фигыльне заман формаларына куя белү.
-текстта синонимнарны һәм антонимнарны таный, сөйләмдә куллана белү.
-сораулар ярдәмендә җөмләдә сүзләрнең бәйләнешен билгеләү, сүзтезмәләрне аеру; сүзтезмәдәге ияртүче һәм ияртүче сүзләрне аеру.
- җөмлә тикшерү (төрен билгеләү, баш һәм иярчен кисәкләрне аера белү)
- бергәләп төзегән план буенча 70 – 85 сүзле изложение язу.
- текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү.
- текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү, кызыл юлны саклау.
- текстның мәгънәле кисәкләре, җөмләләр арасында бәйләнеш булдыру.
- темасыннан яки төп фикереннән чыгып, текстка исем кую.
- хикәяләү, тасвирлау һәм фикер йөртү характерындагы текстларны аера белү.
- шәхси тәҗрибәгә, сюжетлы картинага таянып (алдан әзерлек белән), сочинение язу.
- фикер йөртү характерындагы җавап төзеп әйтү.

**Укучыларның белемен бәяләү системасы**

Укучыларның эшчәнлеген бәяләү белемнәрне үзләштерүне тикшерүдән аларны гамәлдә куллана белүгә күчерелә. *Мәгълүмат чыганаклары:*

— укучыларның эшләре;
— танып белү процессының барышы;
— статистикага нигезләнгән мәгълүматлар;
— тестлар уздыру нәтиҗәләре;
— портфолио.

*Тикшерү алымнары:*

— күзәтүләр;
— мөстәкыйль, контроль эшләр;
— укучыларның әзер җавапны табуы, ирекле кыскача җаваплары;
— ачык җавап;
— үз-үзеңне тикшерү өчен, сораулар куя белү. *Бәяләү критерийлары:*
— җавапларның дөрес һәм дәлилләнгән булуы;
— грамматика кагыйдәләрен куллана белүдә шәхси үсеш;

— әйтмә һәм язма сөйләмнең төгәллеге һәм сәнгатьлелеге үсешендә югарырак баскычка күтәрелү;
— җавапның, уку эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән продуктның сыйфаты; нигезләмәләрнең уйланган булуы;
— мөстәкыйль әйтелгән гипотезаның, аңлатмаларның, язма сөйләм модельләренең дөрес төзелгән булуы;
— сөйләмнең максатчан оештырылуы.

**Укыту- методик,материаль-техник һәм информацион әсбаплар.**

**Программаны тормышка ашыру формалары:**

- - фронталь
- - парларда эш
- - группаларда эш
- - шәхси.

**Программаны тормышка ашыру методлары:**

- - практик;
- - аңлатмалы– иллюстратив;
- - өлешчә -эзләнүле;
- - тикшерүле;
- - күзәтү;
- - проблемалы- эзләнүле;
- - информатив

**Ысуллар һәм чаралар:**

- - модельләр һәм таблицалар;
- - техник чаралар;
- - рәсемнәр;
- - дидактик материаллар.

**Педагогик технологияләр, укыту алымнары.**

- Информацион технологияләр
- Проект технологияләре
- Тикшеренү технологияләре
- Сәламәтлекне саклау технологияләре
- Коммуникатив технологияләр
- Уен технологияләре

- **Укытуның техник алымнары**
- Сыйныф тактасы.
- Магнитофон
- Компьютер
- Сканер
- Принтер
- Фотокамера,видеокамера
- Аудиоязмалар

- Видеофильмнар
- **Интернет ресурслар:**

http://www.farosta.ru-"Умник" Всероссийский детский интернет-фестиваль.
eurekanet.ru- Интернет-ресурсы для школьника:
nachalnyclass.ucoz.ru- сайт для учеников младших классов:
http://www.belem.ru/
adiplar.narod.ru
tatardeti.blogspot.com
tatar.org.ru›kurs/6-tatar-tele/cyr_1.php
tugantelem.narod.ru›tel/nigmatullina.html
Первая помощь - shkola.edu.ru
Школьный портал - portalschool.ru

**Кулланылган укыту-методик комплексы**

1.Татар теле 4 сыйныф , 1, 2 кисәкләр,**дәреслек** И.Х Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова “ Мәгариф- вакыт” нәшрияты 2014 ел
2. И.Х Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова **Методик кулланма**.“ Мәгариф- вакыт” нәшрияты 2014 ел
3. “Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә ана теле укыту: **гомуми программа**” (1 – 4 нче сыйныфлар.Т ө з ү ч е - а в т о р л а р ы : Ч. М. Харисова, И. Х. Мияссарова, Ф. Ш. Гарифуллина; Казан 2011)
4. **Диктантлар җыентыгы** (диск)
5. 1-4 сыйныфлар өчен **язма эшләр**. Казан 2009
6 Интернет ресурслар:
http://www.uchportal.ru(тематик планлаштыру)
http://www.bashmakov.su(контроль эшләр,методик тәкъдимнәр,тематик планлаштыру)
http://www.1september.ru(контроль эшләр саны,”Перспектив башлангыч мәктәбе”укыту-методик комплектына бәяләмә)
http://www.pro shkolu.ru (тематик планлаштыру)
Министерство образования и науки РФ - mon.gov.ru
http://www.suslek.ru/http://www.tatmedia.com.
http://www.tatarstan.ru/books/
http://www.shigriyat.ru/
*http*://www.kitap.net.ru
tarkhanova.ru
gzalilova.narod.ru
tatartele2010.ucoz.ru
tugan-tel.blogspot.com
tatartele5.edu.tatar.ru
belem.ru
forum.tatar.info›index.php
halik-ishati.ucoz.ru
janar.ucoz.ru›publ/i_tugan_tel/i_tugan_tel/
adiplar.narod.ru
tatardeti.blogspot.com
http://www.rusedu.ru/
kitaphane.tatar.ru/sad.htm

**Татар теле фәненнән**

календарь-тематик планлаштыру

**Класс 4**

Укытучы Исрафилова Рәзилә Минегали кызы

Сәгатьләр саны :

Барлыгы:__105__ сәг; атнага __3____сәг.

Планлаштырылган контроль эшләр ____ , диктант ___ , күчереп язу ___сәг;

Административ контроль эшләр__2__сәг.

**Планлаштыру**

“Татарстан Республикасы Фән һәм Мәгариф минстрлыгы” тарафыннан рөхсәт ителгән ” Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программа”(басма өчен җаваплы-Г.Р.Галиуллина,Д.Ф.Заһидуллина, 2011 ел) га нигезләнеп төзелде.

**Дәреслек**

1.Татар теле 1 кисәк, 2 кисәк дәреслек И.Х Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова “ Мәгариф- вакыт” нәшрияты 2013 ел

2. И.Х Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова татар теле мөстәкыйль эш дәфтәре “ Мәгариф- вакыт” нәшрияты 2013 ел

3. И.Х Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова Методик кулланма “ Мәгариф- вакыт” нәшрияты 2013 ел

**Өстәмә әдәбият**

*1. С.Р.САфина. Башлангыч сыйныфлар өчен сочинениеләр. – Казан: “Яңалиф” нәшрияты,2005.*

*2. М.Х. Хәсәнова. Татар теленнән диктантлар.- Казан: Мәгариф, 2006.*

Дәресләрнең чиреклəп бүленеше:
I  чирек — 2 7  сәг.                II чирек — 21 сәг.             III  чирек — 30 сәг.                        IV  чирек - 2

| № | Дәрес темасы<br>Эчтәлек эдементлары | Дәрес тибы | Планлаштырылган таләпләр | | | Укучыларның Эшчәнлек төре | Тикшерү төрләре, формалары | Дата | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | предмет | метапредмет | шәхес | | | План буенча | Факт |
| **1 – 3 сыйныфта үткәннәрне кабатлау – 8 сәг** | | | | | | | | | |
| 1 | 3 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау. Авазлар һәм хәрефләр. Сузык авазлар. Сингармонизм законы. | кереш | **<u>Беләчәк:</u>**<br>аваз һәм хәреф, аларның әйтелеше һәм язылышын, калын һәм нечкә сузыкларны, яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аеру | К<u>оммуникатив</u> планлаштыру<br>**<u>танып-белү</u>**<br>***(Познавательный)***<br>Гомуми уку (общеучебные)<br>-танып-белү максатын билгеләү;<br>-кирәкле информация туплау;<br>**<u>көйләгеч</u>**<br>Максатка ышан | Үзбилгеләмә (самоопределение) | Күнегүләр үтәү | Күнегүләр үтәү | 2.09 | 2.09 |
| 2 | Җәйге истәлекләр буенча сочинение язу | катнаш | **<u>Башкара алачак:</u>**<br>әйтелеш һәм язылышка караган орфограммаларны куллана, сүзләрне иҗеккә бүлә, юлдан-юлга күчерә "Аңлатмалы сүзлек", "Дөрес яз" "Дөрес әйт"сүзлеге | **<u>коммуникатив</u>** Сораулар куелышы<br>Информация табуда һәм туплауда инициативалы бердәмлек<br>**<u>танып-белү</u>**<br>билге-символлар<br>- модельләштерү | Укуның дәлилләре(мотивация учения) | Кагый дә өстендә эшләү | агымдагы коллектив, индивидуаль | 5.09 | |
| 3 | 3 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау. Тартык авазлар. | катнаш | **<u>Беләчәк:</u>**<br>Аваз һәм хәреф аермасы.<br>-сүздән авазны аерып алу, аңа характеристика бирү;<br>Сүзләрне юлдан-юлга күчерә<br>-сүзгә аваз-хәреф схемасын төзү | **<u>Коммуникатив</u>**<br>Иптәшенең үз-үзен тотышы белән идарә итү„фикерне әйтә белү<br>**<u>көйләгеч</u>**<br>***<u>(регулятивный)</u>***<br>Максатка ышану (Целеполагание)<br>Укучылар тарафыннан белгән яки әлегәчә белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү | Шәхеснең гражданлык нигезләре формалашуы (формирование основ гражданской идентичности личности). | Күнегүләр үтәү | агымдагы коллектив, индивидуаль | 6.09 | |
| 4 | 3 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау. Сүзләргә аваз - хәреф анализы. | катнаш | **<u>Беләчәк:</u>**<br>Аваз һәм хәреф аермасы.<br>-сүздән авазны аерып алу, аңа характеристика бирү;<br>Сүзләрне юлдан-юлга күчерә<br>-сүзгә аваз-хәреф схемасын төзү | **<u>Коммуникатив</u>**<br>Планлаштыру<br>Максатны„катнашучыларның функцияләрен,бергәләп эшчәнлекнең алымнарын билгеләү<br>**<u>танып-белү</u>**<br>Гомуми уку (общеучебные)<br>- танып-белү максатын билгеләү;<br>-кирәкле информация туплау; | Мәгънәтөзелеше (Смыслообразования) | Күнегүләр үтәү | агымдагы индивидуаль | 9.09 | |
| 5 | 3 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау. Сүз төркемнәре. | катнаш | **<u>Беләчәк:</u>**<br>Аваз һәм хәреф аермасы.<br>-сүздән авазны аерып алу, аңа характеристика бирү;<br>Сүзләрне юлдан-юлга күчерә<br>-сүзгә аваз-хәреф схемасын төзү | **<u>Коммуникатив</u>**<br>Сораулар куелышы<br>Информациятабуда һәм туплауда инициативалы бердәмлек<br>**<u>көйләгеч</u>**<br>Үз-үзеңне ихтыяр буенча көйләү(волевая саморегуляция) | «минем өчен укунинди мәгънәгә ия», | Күнегүләр үтәү | агымдагы коллектив | 12.09 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | 3 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау. Җөмләнең баш кисәкләре. | катнаш | **Беләчәк:** җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен, сорауларын, табу юлын билгеләнешен **Башкара алачак:** җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен таба, аера, язуда билгели, җөмләдәге сүзләр бәйләнешен ачыклый | **Коммуникатив** Тикшерү, коррекцияләү, иптәшеңнең эшчәнлеген бәяләү,үз фикереңне тулы әйтә белү **танып-белү** чагыштыру,объектларны классларга бүлү, серияләү өчен критерийлар сайлау; | «минем өчен уку нинди мәгънәгә ия», һәм шул сорауга җавап бирә белү. социаль һәм шәхси бәяләрдән чыгып,шәхеснең мораль сайланышында үзләштерү эчтәлеген бәяләү | Кагыйдә өстендә эшләү | агымдагы коллектив, индивидуаль | 13.09 | |
| 7 | 3 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау.План буенча хикәя. | Белем һәм күнекмәләрне тикшерү | **Беләчәк:** язма һәм әйтмә сөйләмне **Башкара алачак:** текстның темасын һәм төп фикерен билгели, мәгънәле кисәкләргә, өлешләргә бүлә, кызыл юлны сайлый, текстка исем куя, төрләрен аера, планын төзи, сюжетлы картинага таянып хикәяләр төзи | **көйләгеч** Үз-үзеңне ихтыяр буенча көйләү(волевая саморегуляция) **танып-белү** төшенчәләрне билгеләү,нәтиҗәләрне чыгару; -сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен ачыклау | социаль һәм шәхси бәяләрдән чыгып,шәхеснең мораль сайланышында үзләштерү | Сүзлекләр белән эшләү | агымдагы коллектив | 16.09 | |
| 8 | Кереш контроль эш. Грамматик биремле диктант. | Белем һәм күнекмәләрне практикада куллану | **Башкара алачак:** текстны грамоталы һәм каллиграфик дөрес итеп күчереп яза | **коммуникатив** Тикшерү, коррекцияләү, иптәшеңнең эшчәнлеген бәяләү,үз фикереңне тулы әйтә белү **танып-белү** чагыштыру,объектларны классларга бүлү, серияләү өчен критерийлар сайлау; | Мәгънәтөзелеше (Смыслообразования) | **Грамматик биремле диктант** | контроль эш | 19.09 | |
| **Сүз. Телнең сүзлек байлыгы – 8 сәг** | | | | | | | | | |
| 9 | Хаталар өстендә эш. Сүзнең лексик мәгънәсе. Лексик төшенчәсен аңлату,аңлатмалы сүзлекләр белән эш,хезмәтләрне бәяләү, төзәтү; татар теленең сүз байлыгы, сүзнең лексик мәгънәсе; лексик мәгънәгә туры килгән сүзләр табу. | катнаш | **Беләчәк:** сүзнең төп мәгънәсен; кушымча төрләрен **Башкара алачак:** сүзләрнең тамырын һәм кушымчасын билгели, әйтелешенә карап тиешле кушымча ялгый; тамырдаш сүзләр таба | **танып-белү** модельләштерү билгеләрне табу максатыннан чыгып, анализлау **коммуникатив** Сораулар куелышы Информация табуда һәм туплауда инициативалы бердәмлек **көйләгеч** Соңгы нәтиҗәләрне исәпкә алып, максатларның эзлеклелеген билгеләү.план төзү һәм эшнең эзлеклелеге | әхлакый-этик бәяләү | Күнегүләр үтәү | агымдагы коллектив, индивидуаль | 20.09 | |
| 10 | Алынма сүзләр. Сүз байлыгы; төрле телләрдән кергән сүзләр, кулланылу | Белем һәм күнекмәләрне практикада куллану | **Беләчәк:** нәрсә ул сүз, сүзнең мәгънәсен; алынма сүзләр, синоним, антоним, омонимнар, искергән һәм яңа сүзләр төшенчәләрен | **танып-белү** танып-белү максатын билгеләү; билге-символлар **коммуникатив** Конфликтларны чишү - табу,проблеманы идентификацияләү,конфликтлар | «минем өчен уку нинди мәгънәгә ия», һәм шул сорауга җавап бирә белү. социаль һәм | Күнегүләр үтәү | агымдагы коллектив, индивидуаль | 23.09 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | өлкәсе. | | | чишелешендә уңай юллар табу,карарлар кабул итүһәм аны тормышка ашыру<br>**кѳйләгеч** Прогнозлау(алдан фаразлау) | шәхси бәяләрдән чыгып,шәхеснең мораль сайланышында үзләштерү эчтәлеген бәяләү | | | | |
| 11 | Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр.<br>Сүзләрнең мәгънәләре, туры һәм күчерелмә мәгънә. | Белем һәм күнекмәләрне практикада куллану | **Беләчәк:**<br>нәрсә ул сүз, сүзнең мәгънәсен; алынма сүзләр, синоним, антоним, омонимнар, искергән һәм яңа сүзләр төшенчәләрен | **танып-белү**<br>житмәгән компонентларны тулыландырып,синтезлау; модельләштерү<br>**коммуникатив**<br>Тикшерү, коррекцияләү, иптәшеңнең эшчәнлеген бәяләү,үз фикереңне тулы әйтә белү<br>**кѳйләгеч**<br>Соңгы нәтиҗәләрне исәпкә алып, максатларның эзлеклелеген билгеләү.план төзү һәм эшнең эзлеклелеге | «минем өчен уку нинди мәгънәгә ия», | Ирекле диктант | тематик эш | 26.09 | |
| 12 | Тотрыклы сүзтезмәләр | катнаш | **Башкара алачак:**<br>сүзлек белән эшли; алынма сүзләрне, синоним, антоним исем, сыйфат фигыльләрне, омонимнарны текстта таный һәм сөйләмдә куллана; сүзнең төп һәм күчерелмә мәгънәләрен билгели | **коммуникатив** Сораулар куелышы Информация табуда һәм туплауда инициативалы бердәмлек<br>**танып-белү**<br>билге-символлар<br>- модельләштерү | Укуның дәлилләре(мотивация учения) | Кагый дә өстендә эшләү | агымдагы коллектив, индивидуаль | 27.09 | |
| 13 | Омонимнар | кереш | **Башкара алачак:**<br>сүзлек белән эшли; алынма сүзләрне, синоним, антоним исем, сыйфат фигыльләрне, омонимнарны текстта таный һәм сөйләмдә куллана; сүзнең төп һәм күчерелмә мәгънәләрен билгели | **танып-белү**<br>кирәкле информация туплау; модельләштерү<br>**коммуникатив**<br>Максатны,,катнашучыларның функцияләрен,бергәләп эшчәнлекнең алымнарын билгеләү<br>**кѳйләгеч** Прогнозлау(алдан фаразлау) | социаль һәм шәхси бәяләрдән чыгып,шәхеснең мораль сайланышында үзләштерү | Сүзлекләр белән эшләү | агымдагы коллектив, индивидуаль | 30.09 | |
| 14 | Синонимнар, антонимнар | Яңа белем нәр форма лаш тыру | **Беләчәк:**<br>нәрсә ул сүз, сүзнең мәгънәсен; алынма сүзләр, синоним, антоним, омонимнар, искергән һәм яңа сүзләр төшенчәләрен | **танып-белү** кирәкле информация туплау; билге-символлар<br>**коммуникатив**<br>Сораулар куелышы<br>Информация табуда һәм туплауда инициативалы бердәмлек | «минем өчен уку нинди мәгънәгә ия», | Кагыйдә өстендә эшләү | агымдагы коллектив | 3.10 | |
| 15 | “Сүзнең лексик мәгънәсе” темасына изложение язу . | Яңа тема | **Башкара алачак:**<br>сүзлек белән эшли; алынма сүзләрне, синоним, антоним исем, сыйфат фигыльләрне, омонимнарны текстта таный һәм сөйләмдә куллана; сүзнең төп һәм күчерелмә мәгънәләрен | **танып-белү** модельләштерү билгеләрне табу максатыннан чыгып, анализлау<br>**коммуникатив**<br>Конфликтларны чишү<br>- табу,проблеманы идентификацияләү,конфликтлар чишелешендә уңай юллар табу,карарлар кабул итүһәм аны | социаль һәм шәхси бәяләрдән чыгып,шәхеснең мораль сайланышында үзләштерү эчтәлеген бәяләү | Күнегүләр үтәү | агымдагы индивидуаль | 7.10 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | билгели | тормышка ашыру | | | | | |
| 16 | Хаталар өстендә эш. Үткәннәрне кабатлауга күнегүләр. | Яңа тема | **Башкара алачак:** сүзлек белән эшли; алынма сүзләрне, синоним, антоним исем, сыйфат фигыльләрне, омонимнарны текстта таный һәм сөйләмдә куллана; сүзнең төп һәм күчерелмә мәгънәләрен билгели | **танып-белү** модельләштерү билгеләрне табу максатыннан чыгып, анализлау **коммуникатив** Конфликтларны чишү - табу,проблеманы идентификацияләү,конфликтлар чишелешендә уңай юллар табу,карарлар кабул итүһәм аны тормышка ашыру | социаль һәм шәхси бәяләрдән чыгып,шәхеснең мораль сайланышында үзләштерү эчтәлеген бәяләү | Күнегүләр үтәү | агымдагы индивидуаль | 10.10 | |
| **Сүз төзелеше – 11 сәг** | | | | | | | | | |
| 17 | Тамыр һәм кушымча | Яңа тема | **Беләчәк:** сүзнең мәгънәле кисәкләре: тамыр һәм кушымчаны **Башкара алачак:** сүзнең тамыр һәм кушымчасын таба, язуда билгели | **танып-белү** Проблеманы кую һәм аны чишү - проблеманың әйтелеше яки бирелеше; эзләнүле һәм иҗади характердагы проблемаларны чишү юлларын мөстәкыйль табу. | Шәхеснең гражданлык нигезләре формалашуы (формирование основ гражданской идентичности личности). | Күнегүләр үтәү Сүзлекләр белән эшләү | агымдагы индивидуаль | 11.10 | |
| 18 | Сүз ясагыч кушымчалар | Яңа тема | **Беләчәк:** ясагыч һәм бәйләгеч кушымчаларны; тамыр, кушма, парлы сүзләрнең ясалышын, кушымчаларны кисәкчәләрдән аера белергә. **Башкара алачак:** сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерә, кушымчаның төрен билгели; тамыр, ясалма, кушма, парлы сүзләрне аерып күрсәтә, сөйләмдә куллана, дөрес яза төрләндергеч һәм сүз ясагыч кушымчаларны аера | **танып-белү** Проблеманы кую һәм аны чишү - проблеманың әйтелеше яки бирелеше; эзләнүле һәм иҗади характердагы проблемаларны чишү юлларын мөстәкыйль табу. | Шәхеснең гражданлык нигезләре формалашуы | Күнегүләр үтәү Сүзлекләр белән эшләү | агымдагы индивидуаль | 14.10 | |
| 19 | Сүз ясагыч кушымчалар | Яңа белемнәр формалаштыру | **Беләчәк:** ясагыч һәм бәйләгеч кушымчаларны; тамыр, кушма, парлы сүзләрнең ясалышын, кушымчаларны кисәкчәләрдән аера белергә. | **танып-белү** житмәгән компонентларны тулыландырып,синтезлау; төшенчәләрне билгеләү,нәтиҗәләрне чыгару; **коммуникатив** Сораулар куелышы Информация табуда һәм туплауда инициативалы бердәмлек | «минем өчен уку нинди мәгънәгә ия», | Күнегүләр үтәү | агымдагы индивидуаль | 17.10 | |
| 20 | Картина буенча сочинение язу . | Яңа белемнәр формалаштыру | **Башкара алачак:** сүзлек белән эшли; алынма сүзләрне, синоним, антоним исем, сыйфат фигыльләрне, омонимнарны текстта таный һәм сөйләмдә куллана; | **танып-белү** гипотезалар китереп чыгару һәм аның нигезе. Проблеманы кую һәм аны чишү - проблеманың әйтелеше яки бирелеше; **коммуникатив** Максатны,,катнашучыларның | Шәхеснең гражданлык нигезләре формалашуы (формирование основ гражданской идентичности | Күнегүләр үтәү | агымдагы коллектив, индивидуаль | 18.10 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | функцияләрен,бергәләп эшчәнлекнең алымнарын билгеләү | личности). | | | | |
| 21 | Төрләндергеч кушымчалар | Яңа белемнәр формалаштыру | **Беләчәк:**<br>ясагыч һәм бәйләгеч кушымчаларны; тамыр, кушма, парлы сүзләрнең ясалышын, кушымчаларны кисәкчәләрдән аера белергә.<br>**Башкара алачак:**<br>сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерә, кушымчаның төрен билгели; тамыр, ясалма, кушма, парлы сүзләрне аерып күрсәтә, сөйләмдә куллана, дөрес яза төрләндергеч һәм сүз ясагыч кушымчаларны | **танып-белү**<br>гипотезалар китереп чыгару һәм аның нигезе. Проблеманы кую һәм аны чишү<br>- проблеманың әйтелеше яки бирелеше;<br>**коммуникатив**<br>Максатны,,катнашучыларның функцияләрен,бергәләп эшчәнлекнең алымнарын билгеләү | Шәхеснең гражданлык нигезләре формалашуы (формирование основ гражданской идентичности личности). | Күнегүләр утәү | агымдагы коллектив, индивидуаль | 21.10 | |
